ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» март 2025 ел № 272

**Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге «Бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип, бакча йортын торак йорт яисә торак йортны бакча йорты дип тану буенча район ведомствоара комиссиясен төзү турында» 1035 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2023 елның 10 октябрендәге 859нчы, 2024 елның 11 гыйнварындагы 3нче номерлы үзгәрешләр белән)**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы “Бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмә” 47 номерлы карарына ярашлы рәвештә Арча муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге “Бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип, бакча йортын торак йорт яисә торак йортны бакча йорты дип тану буенча район ведомствоара комиссиясен төзү турында” 1035 номерлы карарына (2023 елның 10 октябрендәге 859нчы, 2024 елның 11 гыйнварындагы 3нче номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча район ведомствоара комиссиясе составын, әлеге карарга кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны “Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында” (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р. М.Гатиятов

Арча муниципаль районы башкарма
комитеты карарына
Кушымта
24 март 2015 № 272

**Бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча район ведомствоара комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Гатиятов Р.М. | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Хәсәнов И.М. | - Арча муниципаль районының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы, комиссия секретаре; |
| ***Комиссии әгъзалары:*** | |
| Галимуллин И.А. | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Сәгыйтҗанов Р.М. | - "Арча муниципаль районы идарәче компаниясе" ҖЧҖ директоры (килешү буенча); |
| Гатиятов Е.Н. | - "Татарстан Республикасы Техник инвентаризация бюросы" АҖ бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча); |
| Низамутдинов М.М. | - Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең үзәк инспекторлык бүлеге башлыгы (килешү буенча); |

Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе яисә территорияләрендә торак урын булган районның авыл җирлекләре башлыклары(килешү буенча).